Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Советы

Карар

№ 20 от 05 апреля 2016 г

**«Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегендә гражданнарга шәхси торак төзелеше һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелә торган җир кишәрлекләренең чик күләмнәре турында»**

«Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 5 пунктына, Россия Федерациясе җир кодексына, Татарстан Республикасы җир кодексының 34 статьясына ярашлы рәвештә, Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ::

1. Гражданнарга муниципаль милектә булган җирләрдән милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең чик (минималь һәм максималь) күләмнәрен һәм дәүләт милке хокукы чикләнмәгән җирләрне билгеләргә:

0,04 гектардан 0,2 гектарга кадәр мәйданлы шәхси торак төзелеше өчен;

- 0,15 гектардан 0,5 гектарга кадәр шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен.

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://aksubayevo.tatar.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңа Кармәт авыл җирлеге
Советы Рәисе: И.Р.Шакиров